ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» мая 2021 ел № 130

**Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан Әгерҗе муниципаль районы составына керүче «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләүгә бюджетара трансферт бирү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 01 июнендәге 391 номерлы карары нигезендә 2021 елда үткәрелгән республика конкурсы йомгаклары буенча бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 08 апрелендәге 627-р номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан Әгерҗе муниципаль районы составына керүче «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 01 июнендәге 391 номерлы карары нигезендә 2021 елда уздырылган «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләүгә бюджетара трансферт бирергә:

| Муниципаль берәмлек | Территориаль иҗтимагый үзидарә | Бюджетара трансферт сумма, тыс. рублей |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге | «Киров» территориаль иҗтимагый | 160 000 (Бер йөз алтмыш мең) сум 00 тиен. |

| | | |
|---|---|---|
| | үзидарәсе | |

2. 1. Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләүгә бюджетара трансферт бирү турында килешү төзүне тәкъдим итәргә.

3. Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләүгә бюджетара трансферт бирү турында килешүне, яклар имзалаганнан соң, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы А.С. Заитовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**